РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 06 2018 ел. №418

Муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында Нигезләмәне раслау турында

2003 елның 6 октябреннән булган “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ Федераль законны, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июленнән булган “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы №45-ЗРТ Законын, Татарстан Республикасының 2014 елның 7 мартыннан булган “Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларына экспертиза ясу тәртибе турында” №14-ЗРТ Законына, җайга салу карарларын әзерләү һәм кабул итү өлешендә муниципаль идарә процессларының нәтиҗәлелеген күтәрү һәм камилләштерү максатларында, Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты карар итә:

1. Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында теркәлгән Нигезләмәне расларга.

2.Җайга салу йогынтысын бәяләү өлкәсендә вәкаләтле подразделение итеп Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеген билгеләргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының http://jutaza.tatarstan.ru/ рәсми сайтында һәм Татарстан

Республикасы рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru// адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тоту Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С.П. Самонина

Ютазы муниципаль районы Башкарма

Комитеты карарына №1 кушымта

“___” _________ 2018 ел №___

**Муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм норматив-хокукый актларга экспертиза уздыру турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр**

1.Әлеге нигезләмә норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү (алга таба – актлар проектлары) һәм норматив-хокукый актларга экспертиза ясау (алга таба норматив хокукый актлар) уздыру тәртибен эшмәкәрлек һәм инвестицион эшчәнлек субъектлары өчен кирәгеннән артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр керткән яки аларны кертүгә сәбәп булып торган актларны, норматив хокукый актларда гамәлдә булган нигезләмәләрне, эшмәкәрлек һәм инвестицион эшчәнлек субъектларының, муниципаль берәмлек бюджетының нигезсез чыгымнары килеп чыгуга сәбәп булган кагыйдәнамәләрне, эшмәкәрлекне һәм инвестицион эшчәнлекне гамәлгә ашыруны кыенлаштыручы нигезләмәләрне, шулай ук конкуренцияне чикләүгә нигезсез рәвештә сәбәп булган положениеләрне ачыклау өчен билгели.

Җайга салу йогынтысын бәяләү актның эшләнүче проекты аның эшчәнлек өлкәсенә караган муниципаль берәмлек хакимиятенең тармак (функциональ) структур бүлекчәсе (алга таба – профиль подразделениесе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Җайга салу йогынтысын бәяләү өлкәсендә вәкаләтле подразделение булып Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетыныц территориаль үсеш бүлеге тора (алга таба – вәкаләтле подразделение). Вәкаләтле подразделение актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм норматив хокукый актларга экспертиза ясауны уздыруны норматив һәм методик тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

Эшмәкәрлек эшчәнлеген һәм инвестицион эшчәнлекне гамәлгә ашыру сорауларына кагылган актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм норматив хокукый актларга экспертиза ясау җирле үзидарә органнары

тарафыннан 2003 елның 6 октябреннән булган “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга (алга таба - №131-ФЗ Федераль закон), Татарстан Республикасының 2014 елның 7 мартыннан булган “Татарстан республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясауны уздыру тәртибе турында”гы №14-ЗРТ Законына, Татарстан Республикасының 2014 елның 10 маеннан булган “Татарстан Республикасының “Җирле үзидарә турында”гы Законына үзгәрешләр кертү турында”гы №30-ЗРТ законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 31 декабреннән булган “Әлеге нигезләмә һәм башка норматив хокукый актлар белән Татарстан Республикасы дәүләт власте башкарма органнары тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасында гамәлдәге норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының ачык рәвештә җайга салу йогынтысын бәяләү тәртибен раслау турында”гы №1182 карарына ярашлы уздырыла.

2. Эшмәкәрлек эшчәнлеген һәм инвестицион эшчәнлекне тормышка ашыруга кагылган җирле әһәмияттәге түбәндәге сораулар буенча актлар проектлары җайга салу йогынтысын бәяләүгә дучар булырга тиеш *(2013 елның 2 июленнән булган №176-ФЗ Федераль закон аерым муниципаль берәмлек мөнәсәбәтендә көченә кергәнчегә кадәр, хакимият җайга салу йогынтысын бәяләү таралган өлкәләрне сайлауны чикләргә мөмкин):*

1) җирлекнең җирле салымнарын һәм җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару;

2) җирлек чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтү һәм халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итү очен шартлар тудыру;

3) җирлектә яшәүчеләргә элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә хезмәтләре һәм көнкүреш хезмәте күрсәтүне тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

4) җирлектә яшәүчеләрнең ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

5) җирле традицион халык сәнгате иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, җирлектә халык иҗаты кәсбәчелеген саклауда, тергезүдә һәм үстерүдә катнашу;

6) җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән

территорияне планировкалау буенча документацияне раслау, төзелешкә, төзелеш башкарганда объектларны эксплуатациягә кертүгә, җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәтләр бирү, җирлекләр шәһәр төзелеше проектлаштырылуының җирле нормативларын раслау, муниципаль ихтыяҗлар өчен җирлек чикләрендә җир участокларын резервта калдыру һәм алу, шул исәптән, сатып алу юлы белән;

7) авыл хуҗалыгы производствосын үстерүдә булышлык, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыру;

8) җирлек чикләрендә коррупциягә каршы көрәш буенча чараларны гамәлгә ашыру;

9) аерым икътисади зона территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

3. Актлар проектларыныц җайга салу йогынтысын бәяләү акт проектын эшләүче әзерли торган нигезләмәләрнең йогынтысын җайга салу дәрәҗәсен исәпкә алып уздырыла:

1) югары җайга салу йогынтысы дәрәҗәсе – акт проекты элек закончалыкта каралмаган эшмәкәрлек һәм инвестицион эшчәнлек өлкәсендә физик һәм юридик затлар өчен бурычларны, тыюларны, чикләүләрне билгеләүче нигезләмәләрдән, шулай ук элек эшмәкәрлек һәм инвестицион эшчәнлек өлкәсендә закончалыкта каралмаган физик һәм юридик затлар чыгымнар барлыкка килүгә китергән нигезләмәләрдән тора.

2) уртача җайга салу йогынтысы дәрәҗәсе - акт проекты элек закончалыкта каралмаган эшмәкәрлек һәм инвестицион эшчәнлек өлкәсендә физик һәм юридик затлар өчен бурычларны, тыюларны, чикләүләрне үзгәртүче нигезләмәләрдән тора, элек эшмәкәрлек һәм инвестицион эшчәнлек өлкәсендә закончалыкта каралмаган физик һәм юридик затлар чыгымнарының артуына китергән нигезләмәләрдән тора.

3) түбән җайга салу йогынтысы дәрәҗәсе – акт проектында әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында каралган нигезләмәләр юк, эмма, аңа, әлеге нигезләмәгә ярашлы, җайга салу йогынтысы бәяләмәсе уздырылырга тиеш.

4. Дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар, конфиденциаль характердагы мәгълүматлары булган яки норматив хокукый актларга аларга федераль һәм региональ закончалыкка яраклаштыру өчен үзгәрешләр кертүгә

юнәлтелгән, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләргә юл куймау максатында, кризис вазгыятьләренә һәм террорчылык актларын кисәтүгә һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү максатында эшләнгән проектларның җайга салу йогынтысын бәяләү уздырылмый.

5. Норматив-хокукый актлар экспертизасы (алга таба – экспертиза) аларны уздыруның еллык планарына ярашлы вәкаләтле подразделение тарафыннан үткәрелә.

6. Норматив-хокукый акт экспертизасы (алга таба – экспертиза) уздыру өчен нигез булып муниципаль берәмлекнең хакимият башлыгы йөкләмәсе яки боерыгы, эшмәкәрлек, инвестицион эшчәнлек, кулланучылар берләшмәләре, үзкөйләнүче оешмалар, фәнни-эксперт оешмалары, җирле үзидарә органнары өлкәсендә иҗтимагый оешмалардан тәкъдимнәр, профилье подразделениенең эшмәкәрлек һәм инвестицион эшчәнлек өлкәләрендә проблемалар булуын ачыклау, шул исәптән түбәндәгеләр нәтиҗәсендә:

1) норматив хокукый актлар мониторингы, шул исәптән муниципаль максатлы программаларны гамәлгә ашыру мониторингы;

2) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади торышы мониторингы;

3) җирле үзидарә органнарына гражданнарның һәм оешмаларның эшмәкәрлек, инвестицион эшчәнлекнең билгеле бер өлкәсендә проблема булуы турында күп тапкыр мөрәҗәгатьләре керүе;

7. Экспертиза түбәндәгеләр мөнәсәбәтендә үткәрелә:

1) норматив хокукый актларны җайга салу йогынтысын бәяләүне уздырганда, норматив-хокукый актларның югары җайга салу йогынтысы югары дип билгеләнгәндә һәм аларның көченә керүенә оч елдан ким булмаган вакыт узганда;

2) акт проектын эшләү стадиясендә җайга салу йогынтысын бәяләүне узмаган норматив хокукый актлар һәм аларның көченә керү моментыннан бер елдан ким булмаган вакыт узганда, экспертизаларын уздырганда Свердловск олкәсе дәүләт власте органнарыннан, эшчәнлек максатлары җайга салу йогынтысын бәяләүне уздырганда эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектлары мәнфәгатьләрен яклау булган җирле үзидарә органнанры, эксперт оешмалары, хезмәттәшлек турында килешү төзелгән оешмалар, шулай ук башка затлар мөнәсәбәтендә .

8. Дәүләт серен тәшкил иткән, яки кофединциаль төрдәге мәгълүматлары булган, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш вазгыятьләрнең, кризис вазгыятьләренең килеп чыгуына юл куймау һәм бетерү һәм террорчылык актларын кисәтү, һәм (яки) аларның нәтиҗәләрен бетерү максатында эшләнгән норматив хокукый актлар экспертизасы уздырылмый.

9. Актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм норматив-хокукый актларның экспертизасы өчен рәсми сайт булып Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/rus/otsenka-reguliruyushchego-vozdeystviya.htm (алга таба – рәсми сайт) тора.

**2 бүлек. Муниципаль-норматив хокукый актлар проектларына җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру**

10. Акт проектына җага салу йогынтысын бәяләүне уздыру этаплары булып тора:

1) профильле подразделениегә җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру өчен акт проектын һәм җыелма отчет җибәрү;

2) акт проекты һәм җыелма отчет буенча ачык консультацияләр уздыру;

3) акт проектының җайга салу йогынтысын бәяләү турында эксперт нәтиҗәсен хәзерләү;

4) җайга салу йогынтысын бәяләү турында нәтиҗәне аны эшләүчегә юнәлтү.

Әгәр эшләүче һәм профильле подразделение бер үк бүлекчә булса, 1 һәм 4 этаплар гамәлгә ашырылмый.

11. Җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру методологиясе вәкаләтле подразделение тарафыннан раслана.

12. Җыелма отчетта түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) акт проектының җайга салу йогынтысы дәрәҗәсе;

2) муниципаль җайга салу, аның сәбәпләре, вакыт эчендә проблеманың үсеш динамикасы һәм прогнозы;

3) хәзерге вакытта аларга ярашлы муниципаль җайга салу гамәлгә ашырылган норматив-хокукый актлар һәм аларның аерым нигезләмәләре;

4) проблемадан арыну (негатив тәэсирен минимальләштерү), шул исәптән, хокук куллану практикасын камилләштерү, шулай ук норматив хокукый актларны эшләү, үзгәртү яки гамәлдән чыгару вариантлары;

5) муниципаль җайга салу максатлары;

6) муниципаль җайга салу юнәлтелгән эшмәкәрлек, инвестицион эшчәнлек субъектлары төркеменә харктеристика;

7) җирле үзидарә органнарының яңа функцияләре, вәкаләтләре, бурычлары һәм хокуклары яки аларның үзгәрүе турында мәгълүмат, шулай ук аларны гамәлгә ашыру тәртибе;

8) билгеләнгән бурычларны һәм чикләүләрне үтәү яки мондый бурычларны яки чикләүләрнең эчтәлеген үзгәртү белән бәйле муниципаль бюджет, эшмәкәрлек эшчәнлеге һәм инвестицион эшчәнлек субъектлары чыгымнарын (мөмкин булган керемнәрне) бәяләү;

9) муниципаль җайга салу олкәсендә ачыкланган проблема торышын чагылдырган максатларга ирешү мониторингы индикаторлары (күрсәткечләре), җайга салу өлкәсендә проблемага анализ уздыру моментына әлеге индикаторлар әһәмияте индикаторы һәм индикаторлар мәгълүмат чыганаклары;

10) акт проекты файдасын һәм чыгымнарын җентекләп язу:

социаль төркемнәр, икътисади секторлар, йогынты ясалачак территорияләр; көтелгән негатив һәм позитив йогынты, тиешле йогынтыны сыйфатлы итеп бәян итү, һәм, әгәр мөмкин булса, аның күләм бәяләмәсе, шулай ук тиешле йогынты чоры (кыска-, уртача- яки озак вакытлы);

11) норматив-хокукый акт кабул итү белән бәйле рискларны һәм чыгымнарны бәяләү;

12) норматив-хокукый акт кабул итү белән бәйле көтелгән нәтиҗәләр, рисклар һәм чикләүләр.

13) акт проекты көченә керүенең күздә тотылган датасы;

14) җайга салу максатына ирешү сайланган ысулының нәтиҗәлелеген контрольдә тоту методларын күрсәтү;

15) җайга салуның билгеләнгән максатларына ирешү өчен мөһим булган оештыру-техник, методологик, мәгълүмати һәм башка чаралар;

16) белдерүне урнаштыру, мондый урнаштыру белән бәйле тәкъдимнәр сроклары турында мәгълүмат;

17) җайга салучы (разработчик) фикере буенча тәкъдим ителгән җайга салуның нигезлелеген бәяләргә мөмкинлек биргән башка мәгълүматлар.

**3 бүлек. Муниципаль норматив хокукый актлар проектлары буенча ачык консультацияләр уздыру**

13) Ачык консультацияләр уздыру өчен Профильле подразделение рәсми сайтта уведомление, акт проекты һәм җыелма отчет урнаштыра.

14) Уведомлениегә профильле подразделение җитәкчесе яки аның урынбасары кул куя һәм анда түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) актның төре, исеме, планлаштырылган көченә керү срогы;

2) уведомлениене урнаштыру белән бәйле, аның дәвамында җайга салучы тарафыннан тәкъдимнәр кабул ителгән срок һәм аларны тапшыруның аеруча уңайлы ысулы.

16. Профильле подразделение уведомлениене урнаштыру белән бәйле билгеләнгән срокта кергән барлык тәкъдимнәрне карарга һәм аларның учеты турында мәгълүматларны яки кире кагу турында сәбәпләрен күрсәтеп, тәкъдимнәр исемлеген төзергә бурычлы, аңа профильле подразделение җитәкчесе кул куя.

17. Түбән җайга салу йогынтысы дәрәҗәсе булган актлар проектлары буенча ачык консультацияләр уздыру сроклары 10 календарь көн тәшкил итә, уртача җайга салу дәрәҗәсе йогынтысы булганда – 20 календарь көн, югары җайга салу дәрәҗәсе булганда – 30 календарь көн.

18. Ачык консультацияләр максатлары булып тора:

1) акт проекты максатларының адекватлыгын, максатларга ирешү срокларын, аларга ирешү күрсәткечләрен раслау;

2) акт проектында эшмәкәрлек, инвестицион эшчәнлек субъектлары өчен кирәгеннән артык административ һәм башка чикләүләр һәм бурычлар керткән яки аларны кертүгә сәбәп булган нигезләмәләрне ачыклау;

3) эшмәкәрлек, инвестицион эшчәнлек субъектларының, муниципаль берәмлек бюджетының нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә сәбәп булып торган нигезләмәләрне ачыклау;

4) эшмәкәрлек, инвестицион эшчәнлек субъектлары өчен, шулай ук тулаем җәмгыять өчен акт проектының файдасын һәм чыгымнарын бәяләүләрне, шулай ук акт проекты максатларына ирешмәүнең куркынычларын (риски) ачыклау;

5) норматив хокукый акт кертүнең вакыт белән ераклаштырылган нәтиҗәләренә бәя бирү.

19. Акт проекты буенча ачык консультация уздыру нәтиҗәләре буенча профильле подразделение тарафыннан акт проектының җайга салу йогынтысын бәяләү турында нәтиҗә әзерләү гамәлгә ашырыла, ул үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

1) ачык консультацияләр нәтиҗәләре буенча эшләнеп бетелгән җыелма отчет;

2) акт проекты буенча тәкъдимнәр җыелмасы.

20. Нәтиҗәгә профильле подразделение җитәкчесе һәм аның урынбасары кул куя һәм аңа кул куйганнан соң, ул 5 эш көне дәвамында рәсми сайтта урнаштырыла.

**4 бүлек. Җайга салу йогынтысын бәяләү нәтиҗәләрен файдалану тәртибе**

21. Муниципаль норматив-хокукый акт проектының җайга салу йогынтысын бәяләү турында нәтиҗә һәм аның буенча ачык консультацияләрдә катнашучылардан кергән тәкъдимнәр җыелмасы профильле подразделение тарафыннан әлеге муниципаль хокукый акт проектын эшләүчегә һәм вәкаләтле подразделениегә ачык консультацияләр тәмамлану көненнән соң 10 календарь көннән дә соңламыйча җибәрелә.

22. Ачык консультацияләр нәтиҗәләре буенча, акт проектында әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләр ачыкланган очракта, эшләүче акт проектын әзерләүдән яки аны эшләп бетерүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Акт проектын әзерләүдән яки аны эшләп бетерүдән баш тарту турында карар кабул итү очрагында, эшләүче җайга салу йогынтысын бәяләү турында нәтиҗә һәм акт проекты буенча тәкъдимнәр җыелмасы алганнан көннән соң 15 коннән дә соңламыйча рәсми сайтта тиешле мәгълүматны урнаштыра.

Акт проектында әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләр булмавы ачыкланса, эшләүче акт проектының ахыргы редакциясен, шулай ук акт проекты буенча ачык консультацияләрдә катнашучылардан кергән тәкъдимнәр исемлегендә алынган учетка алу яки тәкъдимнәрне читкә кагу турында мәгълүматны, җайга салу йогынтысын бәяләү турында нәтиҗә һәм акт проекты буенча тәкъдимнәр җыелмасын алган көннән соң 15 календарь көннән дә соңламыйча хәзерли.

23. Эшләүче (разработчик) тарафыннан акт проекты буенча җайга салу йогынтысын бәяләү турында нәтиҗә һәм тәкъдимнәр җыелмасы алынган көннән соң, 20 көннән дә соңламыйча, разработчик вәкаләтле подразделениегә акт проектының соңгы редакциясе күчермәсен, шулай ук акт проекты буенча ачык консультацияләрдә катнашучылардан кергән тәкъдимнәр җыелмасында алынган тәкъдимнәрне учетка алу һәм тәкъдимнәрне кире кагу турында күчермәне җибәрә.

24. Вәкаләтле подразделение тарафыннан соңгы редакция күчермәсе алынган көннән соң 5 эш көненнән дә соңламыйча, шулай ук акт проекты буенча ачык консультацияләрдә катнашучылардан кергән тәкъдимнәр исемлегендә булган тәкъдимнәрне учетка алу яки кире кагу сәбәпләре турында вәкаләтле орган әлеге документларны, шулай ук җайга салу йогынтысын бәяләү турында нәтиҗә күчермәсен һәм тәкъдимнәр җыелмасы күчермәсен рәсми сайтта урнаштыра.

**5 бүлек. Муниципаль норматив хокукый актлар экспертизасын уздыру**

25. Норматив хокукый актлар экспертизасын уздыру этаплары булып түбәндәгеләр тора:

1) норматив хокукый актлар экспертизасы уздыру планын формалаштыру (алга таба – План);

2) норматив хокукый актлар экспертизасы нәтиҗәләре турында йомгаклау олеше проектлары әзерләү;

3) норматив хокукый актлар экспертизасы нәтиҗәләре турында йомгаклау өлеше проектлары буенча ачык консультацияләр уздыру;

4) норматив хокукый актлар нәтиҗәләре турында йомгаклау өлешен әзерләү.

26. Муниципаль хокукый актлар экспертизасын уздыру методологиясе вәкаләтле подразделение тарафыннан раслана.

27. Норматив хокукый актлар экспертизасы, расланган Планга ярашлы, Вәкаләтле подразделение тарафыннан уздырыла.

## 6 бүлек. Норматив хокукый акт экспертизасын уздыру планын әзерләү

28. Планда күрсәтелә:

1) норматив хокукый акт исеме һәм реквизитлары;

2) хокукый актны эшләүне гамәлгә ашырган җайга салу органының, подразделениенең исеме;

3) норматив хокукый акт экспертизасы турында нәтиҗә проектын тапшыру срогы;

4) норматив хокукый акт экспертизасы, шул исәптән ачык консультацияләр уздыру срогы.

29. Вәкаләтле подразделение агымдагы ел тәмамланганга кадәр 4 айдан да соңламыйча рәсми сайтта План формалаштыру максатларында тәкъдимнәр җыю турында белдерү урнаштыра.

30. Тәкъдимнәр җыю срогы белдерү урнаштырылган мизгелдән 45 календарь көннән артмый.

31. Тәкъдимнәр җыю срогы тәмамлану көненнән соң, 5 эш көненнән дә соңламыйча, вәкаләтле подразделение норматив хокукый актларны киләсе елга планга кертү буенча барлык кергән тәкъдимнәр җыелмасын формалаштыра һәм ачык консультацияләр максатларында аны рәсми сайтка урнаштыра.

32. Тәкъдимнәрне планга кертү буенча ачык консультацияләр срогы 30 календарь көннән дә ким тәшкил итми.

33. Ачык консультацияләр нәтиҗәләре буенча вәкаләтле подразделение киләсе елга планны формалаштыра һәм раслый.

План, аны раслаган көннән соң, 5 эш көненнән дә соңламыйча рәсми сайтта урнаштырылырга тиеш.

**7 бүлек. Норматив хокукый актлар экспертизасы нәтиҗәләре турында йомгаклау проектларын әзерләү һәм алар буенча ачык консультацияләр уздыру**

34. Норматив-хокукый актлар экспертизасы нәтиҗәләре турында йомгаклау һәм аның проектында түбәндәге мәгълүматлар бар:

1) норматив хокукый актның топ реквизитлары;

2) норматив хокукый актны кабул иткән һәм (яки) тикшерелгән иҗтимагый мөнәсәбәтләр өлкәсе аның компетенңиясенә һәм вәкаләтләренә мөнәсәбәтле булган органның исеме;

3) акт проектының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру нәтиҗәләре турында мәгълүмат (аны уздыру очрагында);

4) каралучы норматив хокукый актның һәм аның нигезләмәләренең гамәлдә булу срогы;

5) билгеләнгән норматив хокукый акт белән мәнфәгатьләрен җайга салу аларга кагылган затлар даирәсе (алга таба – җайга салу);

6) проблеманы хәл итү дәрәҗәсен бәяләү һәм җайга салу хисабына аның белән бәйле негатив нәтиҗәләрне җиңеп чыгу;

7) әлеге норматив хокукый актны гамәлгә ашырудан чыгымнарны һәм табышларны бәяләү;

8) җайга салуның фактик уңай һәм кире нәтиҗәләрен бәяләү;

9) белдерелгән максатларга һәм җайга салу күрсәткечләренә ирешү нәтиҗәлелеген бәяләү;

10) норматив хокукый актта эшмәкәрлекне һәм инвестиңион эшчәнлекне һәм (яки) башка эшчәнлекне алып баруны нигезсез авырлаштырган нигезләмәләр булу турында мәгълүмат;

11) эшмәкәрлек эшчәнлеген һәм инвестицион эшчәнлекне нигезсез рәвештә авырлаштырган нигезләмәләрдән арыну һәм гамәлдәге җайга салу нәтиҗәлелеген арттыру ысуллары турында тәкъдимнәр;

12) фактта җайга салу йогынтысын бәяләргә мөмкинлек биргән башка мәгълүматлар.

35. Норматив хокукый акт экспертизасы нәтиҗәләре турында йомгаклау өлеше проекты профильле подразделение тарафыннан әзерләнә һәм вәкаләтле подразделениегә юнәлтелә.

36. Норматив хокукый актлар нәтиҗәләре турында йомгаклау өлеше проекты вәкаләтле подразделение тарафыннан Планда билгеләнгән срокларда ачык консультациягә чыгарыла.

Норматив хокукый актлар экспертизасы нәтиҗәләре турында йомгаклау проектлары буенча ачык консультацияләр уздыру өчен вәкаләтле подразделение рәсми сайтта аларны уздыру турында белдерү, аның буенча экспертиза уздырылган норматив хокукый актны, норматив хокукый акт нәтиҗәләре турында йомгаклау проектын урнаштыра.

37. Белдерүдә шулай ук ачык консультацияләр уздыру срогы һәм ачык консультацияләрдә катнашучылар тарафыннан үз фикерләрен юнәлтү ысулы күрсәтелергә тиеш.

38. Норматив хокукый актлар экспертизасы проектлары буенча ачык консультацияләр уздыру сроклары 20 календарь көннән ким һәм 30 календарь көннән артык булырга тиеш түгел.

39. Вәкаләтле подразделение ачык консультацияләр нәтиҗәләре буенча кергән барлык тәкъдимнәрне карарга һәм аларның учеты яки кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, тәкъдимнәр җыелмасын төзергә бурычлы.

Норматив хокукый актлар экспертизасы нәтиҗәләре турында йомгаклау проектлары буенча ачык консультацияләр уздыру нәтиҗәләре буенча вәкаләтле подразделение тарафыннан норматив хокукый актлар экспертизасы нәтиҗәләре турында йомгаклау өлеше әзерләү гамәлгә ашырыла.

40. Норматив хокукый актлар экспертизасы нәтиҗәләре турында йомгаклауларга вәкаләтле подразделение башлыгы тарафыннан кул куела һәм имза куелга көннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча рәсми сайтта урнаштылырга тиеш.

**8 бүлек. Экспертиза нәтиҗәләрен файдалану тәртибе**

41. Норматив хокукый актлар экспертизасы нәтиҗәләренең йомгаклау өлеше муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү яки аларны гамәлдән чыгару өчен нигез булып торырга мөмкин.

42. Норматив хокукый акт экспертизасы нәтиҗәләренең йомгаклау өлешенә кул куелганнан соң, 10 эш көне дәвамында ул Профильле подразделениегә җибәрелә. Вәкаләтле подразделение экспертиза нәтиҗәләре буенча муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында муниципаль берәмлек башлыгы адресына тәкъдимнәр җибәрергә мөмкин.